СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.03.2022 г.Лениногорск № 17

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 8 августындагы 55 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасы һәм муниципаль вазыйфалар, биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лениногорск муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 259-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.4 өлеше, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.3 өлешен гамәлгә ашыру максатларында, Лениногорск шәһәре прокуратурасының 2022 елның 7 мартындагы 02-08-03 номерлы протестын карап, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 8 августындагы 55 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасы һәм муниципаль вазыйфалар, биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лениногорск муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

3 пунктның «г» пунктчасында «акцияләр (оешмаларның устав (җыю) капиталларында пайларның катнашу өлеше)» сүзләреннән соң «цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары С.В. Тимаковка йөкләргә.

3. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында http://leninogorsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск
муниципаль районы Башлыгы,
Совет рәисе Р.Г.Хөсәенов